СОВЕТ УСАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4, с. Усали,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮСӘЛИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Беренче Май ур., 4 нче йорт, Үсәли авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Решение

«15» апрель, 2024 ел — № 3-34

«Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәне раслау турында» 2009 елның 18 июнендәге 2-38 номерлы Үсәли авыл җирлеге карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы» нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәне раслау турында» 2009 елның 18 июнендәге 2-38 номерлы Үсәли авыл җирлеге карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.6 пунктта «Белешмәләр» сүзеннән соң «(анкетада күрсәтелгән белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Үсәли авыл җирлеге башлыгы А.И.Зиатдиновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Үсәли авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе — /А.И.Зиатдинов/